# Җир тетрәнә

*Казанның һәлак булган 175-нче мәктәбе укучыларына багышлана*

Җир тетрәнә, мондый фаҗигане,

Раббым күрсәтмәсен беркемгә.

Ата-анасын, туган йортын ташлап,

Китте алар, китте мәңгегә.

Кемгә кирәк булды бу яшьләрнең,

Гомерләрен шулай өзәргә?

Бер гәепсез килеш кара гүргә,

Ата-анага ничек түзәргә?

Елый йөрәк, ага күздән яшьләр,

Үлем аера ата-анадан.

Олы уйлар бар да артта калды,

Алар китте олы җиһаннан.

*Мехаматнур Нәҗметдинов, 2021 ел, 14 май*